СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 2-2 от « 14 » ноября 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Максатка ярашлылыктан чыгып, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2025 елның 22 сентябрендәге 6-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Дополнить Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге 21.1 пункт өстәргә:

«21.1. Конкурс комиссиясе утырышында шәхсән катнаша алмаган очракта, конкурс комиссиясе рәисе белән килештереп, комиссия әгъзалары, мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып, видеоконференцэлемтә режимында конкурс комиссиясе утырышында дистанцион режимда катнаша алалар, бу хакта конкурс комиссиясе утырышының тиешле беркетмәсендә күрсәтелә.

Конкурс комиссиясе утырышын дистанцион режимда уздыру өчен тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең дөреслеген тәэмин итә торган электрон яисә башка элемтә кулланыла.

Конкурс комиссиясе утырышында дистанцион режимда катнашкан комиссия әгъзасы конкурс комиссиясе утырышында катнаша дип санала.

Комиссия утырышында дистанцион режимда катнашучы Конкурс комиссиясе әгъзаларын тавыш бирү сораштыру юлы белән, шулай ук утырыш башында конкурс комиссиясе әгъзалары билгеләгән кулларны күтәреп яисә башка ысуллар белән уздырыла.»

1.2. 23 һәм 24 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

000110

«23. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре карар белән рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышын уздырганнан соң ук утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

Конкурс комиссиясе утырышы дистанцион режимда уздырылган очракта, карар җиде календарь көн эчендә утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

24. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турындагы мәгълүмат Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан район Советына комиссия карарына имза салынганнан соң өч көн эчендә тапшырыла.» .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И. Никитин